Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2015 елның 12 феврале 7№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында**

2009 елның 09 февралендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 8-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 16 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи авыл җирлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Расларга:

1) Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында нигезләмә (1 нче кушымта);sub_100

2) Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге (2 нче кушымта).sub_200

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи авыл җирлеге мәгълүмат стендында урнаштырырга

Әлки муниципаль районы Тубән Кәчи авыл җирлеге Советы рәисе М.И.Елифанов

Әлки муниципаль
районы Түбән Кәчи
авыл җирлеге
Советының 2015. 12.02,
7№ карарына
1 нче кушымта

**Әлки муниципаль районының Түбән Кечи авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи авыл җирлеге органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакындагы әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) 2009 елның 9 февралендәге "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында" 8-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 16 гыйнварындагы "Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи авыл җирлеге уставы нигезендә эшләнгән һәм гражданнарның Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алу хокукын гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба - мәгълүмат).

2. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә хәл ителергә тиеш.

## 2. Мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүнең төп принциплары

Мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүнең төп принциплары:

1) «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

2) мәгълүмат күрсәтүнең дөреслеге һәм үз вакытында башкарылуы;

3) теләсә нинди законлы ысул белән мәгълүмат эзләү, алу, тапшыру һәм тарату иреге,

4) Мәгълүмат биргәндә гражданнарның хосусый тормышының кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә хокукларын үтәү, аларның намусын һәм эшлекле абруен яклау, оешмаларның аларның эшлекле абруен яклау хокукы.

## 3. Мөмкинлеге чикләнгән мәгълүмат

1. Әлеге мәгълүмат Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләргә кертелгән очракта мәгълүматтан файдалану чикләнә.

2. Файдалануы чикләнгән мәгълүматка кагылышлы белешмәләр исемлеге, шулай ук күрсәтелгән белешмәләрне чикләнгән мәгълүматка кертү тәртибе Федераль закон белән билгеләнә.

### 4. Мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү ысуллары

Мәгълүматтан файдалану ысуллары:

1)Мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару;

2) «Интернет» челтәрендә мәгълүмат урнаштыру;

3) җирле үзидарә органнары били торган биналарда һәм шушы максатлар өчен билгеләнгән башка урыннарда мәгълүмат урнаштыру;

4) кулланучыларны мәгълүмат белән җирле үзидарә органнары били торган биналарда, шулай ук китапханә һәм архив фондлары аша таныштыру;

5) гражданнар (физик затлар), шул исәптән оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи авыл җирлеге советы утырышларында, җирле үзидарә органнарының регламентлары яисә башка хокукый актлары нигезендә җирле үзидарәнең коллегиаль органнары утырышларында катнашу;

6) кулланучыларга аларның соравы буенча мәгълүмат бирү;

7) законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда, шулай ук муниципаль норматив хокукый актларда каралган башка ысуллар белән.

### 5. Мәгълүматтан файдаланучының хокуклары

Мәгълүмат кулланучы хокуклы:

1) дөрес мәгълүмат алырга;

2) мәгълүмат алудан баш тартырга;

3) керү мөмкинлеге чикләнмәгән соралган мәгълүматны алу кирәклеген нигезләмәскә;

4) җирле үзидарә органнарының, аларның вазыйфаи затларының мәгълүматтан файдалану хокукын һәм аны гамәлгә ашыруның билгеләнгән тәртибен боза торган актларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә;

5) мәгълүматтан файдалану хокукын бозуга китергән зыянны законда билгеләнгән тәртиптә түләтүне таләп итәргә.

### 6. Мәгълүмат бирү рәвеше

1. Мәгълүмат телдән һәм документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә бирелә.

2. Мәгълүмат бирү рәвеше Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә. Мәгълүмат бирү формасы ачыкланмаган очракта, ул кулланучының соравы белән билгеләнә. Күрсәтелгән мәгълүматны соралган формада бирү мөмкин булмаса, мәгълүмат аның җирле үзидарә органында булган рәвештә бирелә.

3.Телдән мәгълүмат мәгълүмат кулланучыларга кабул итү вакытында бирелә. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук җирле үзидарә органының белешмә хезмәтләре телефоннары буенча яки җирле үзидарә органы тарафыннан

вәкаләтле вазыйфаи затларның телефоннары буенча да бирелә.

4. Мәгълүмат гомуми файдаланудагы элемтә челтәрләре буенча тапшырылырга мөмкин.

## 7. Мәгълүматтан файдалануны оештыру

1. Мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә тәэмин ителә.

2. Җирле үзидарә органнары мәгълүматтан файдалануны оештыру максатларында:

1) массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүматны бастырып чыгаруны тәэмин итәләр;

2) «Интернет» челтәреннән файдаланып мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайт төзиләр (билгелиләр);

3) тиешле структур бүлекчәләрне яисә вәкаләтле вазыйфаи затларны билгелиләр, шулай ук күрсәтелгән бүлекчәләрнең һәм вазыйфаи затларның хокукларын һәм бурычларын билгелиләр.

## 8. Җирле үзидарә органнары били торган биналарда, шулай ук китапханә һәм архив фондлары аша мәгълүмат белән таныштыру

1. Җирле үзидарә органнары карары буенча алар билгеләгән тәртиптә мәгълүматтан файдаланучыга әлеге органнар биләгән биналарда мәгълүмат белән танышу мөмкинлеге бирелергә мөмкин.

2. Китапханә һәм архив фондларында булган мәгълүмат белән мәгълүматтан файдаланучыларны таныштыру Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 9. «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру

1. Җирле үзидарә органнары Мәгълүматны урнаштыру өчен «Интернет» челтәреннән файдаланалар, анда, мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан сорау җибәрелергә һәм соратып алынырга мөмкин булган электрон почта адресларын күрсәтеп, рәсми сайт төзиләр.

2. Әлеге бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматтан файдаланучылар файдалана алырлык урыннарда (җирле үзидарә органнары, муниципаль китапханәләр биналарында, урыннарда йөрү мөмкинлеге булган башка урыннарда) чикләнмәгән затлар даирәсенең хокукын тәэмин итү максатларында «Интернет» челтәренә тоташтыру пунктлары төзелә.

3. Әлеге бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматтан файдаланучыларның хокукларын тәэмин итү максатларында җирле үзидарә органнары әлеге мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген Россия Федерациясе законнары нигезендә яклау чараларын күрә.

## 10. Мәгълүматны бастырып чыгару

1. Массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүматны бастырып чыгару, әлеге бүлекнең 2 һәм 3 пунктларында каралган очраклардан тыш, массакүләм

мәгълүмат чаралары турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар өчен мондый мәгълүматны бастырып чыгаруга таләпләр каралган булса, аны бастырып чыгару шушы таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3. Җирле үзидарә органнарының хокукый актларын рәсми бастырып чыгару Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында, җирле үзидарә органнарының хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә аларны рәсми бастырып чыгару тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 11. Мөрәҗәгать буенча мәгълүмат бирү тәртибе

1. Мәгълүматтан файдаланучы турыдан-туры, шулай ук үз вәкиле аша да мөрәҗәгать белән җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы, аның вәкаләтләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелә.

2. Мөрәҗәгатьтә сорауга яисә аның әчтәлеген төгәлләштерүгә җавап җибәрү өчен почта адресы, телефон номеры һәм (яисә) факс адресы, шулай ук гражданның (физик затның) фамилиясе, исеме һәм атасының исеме яисә оешманың (юридик затның), иҗтимагый берләшмәнең, дәүләт органының, җирле үзидарә органының исеме күрсәтелә.

Аноним сораулар каралмый.

Язма рәвештә төзелгән мөрәҗәгатьтә шулай ук сорау җибәрелә торган җирле үзидарә органының исеме, яки тиешле вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары яисә вазыйфаи заты вазыйфасы күрсәтелә.

3. Мөрәҗәгать язганда Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының дәүләт теле кулланыла.

Җирле үзидарә органына чит телдә төзелгән мөрәҗәгать кергән очракта, әлеге мөрәҗәгать җирле үзидарәнең тиешле органы билгеләгән тәртиптә каралырга мөмкин.

4. Язма рәвештә төзелгән мөрәҗәгать тиешле җирле үзидарә органына кергән көннән алып өч көн эчендә теркәлергә тиеш. Телдән бирелгән мөрәҗәгать шул ук көнне датасын һәм вакытын күрсәтеп теркәлергә тиеш.

5. Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, мөрәҗәгать теркәгән көннән алып утыз көн эчендә каралырга тиеш. Соратып алына торган мәгълүматны күрсәтелгән срокта бирү мөмкин булмаса, мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң җиде көн эчендә Мәгълүматтан файдаланучыга соратып алына торган мәгълүматны бирүнең сәбәбен һәм вакытын күрсәтеп, җавапны кичектереп тору турында хәбәр ителә, ул 2009 елның 9 февралендәге "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 8-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпкә җавап бирү срогыннан, унбиш көннән дә артмаска тиеш.garantF1://94874.0

6. Әгәр мөрәҗәгать җирле үзидарә органы эшчәнлегенә кагылмаса, мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә ул соратып алынучы мәгълүмат бирү вәкаләтләренә кертелгән органнарга җибәрелә. Сорауны шул ук срокта яңадан адреслау турында мөрәҗәгать иткән кулланучыга мәгълүмат белән хәбәр ителә. Әгәр җирле үзидарә органының соратып алына торган мәгълүматның башка органнарда барлыгы турында белешмәләре булмаса, бу хакта шулай ук мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгать юллаган кешегә хәбәр ителә.

7. Мөрәҗәгатькә язма рәвештә һәм аңа җавапка куела торган таләпләр «Интернет» челтәреннән, шулай ук мондый сорауга җавапка карата кулланыла.

8. Мөрәҗәгатькә җавапта сорала торган мәгълүмат булырга яисә аның кушымтасын күздә тотарга яки мондый мәгълүмат бирүдән нигезле рәвештә баш тартылырга тиеш. Мөрәҗәгатькә җавапта җирле үзидарә органының исеме, почта адресы, җавабын имзалаган зат вазыйфасы, шулай ук сорауга җавап реквизитлары (теркәү номеры һәм датасы) күрсәтелә.

9. Мөрәҗәгатькә җавап биргәндә Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының дәүләт теле кулланыла.

10. Массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан яки «Интернет» челтәрендә урнаштырылган мәгълүмат соратылганда, җирле үзидарә органы соратып алуга җавап итеп соратып алына торган Мәгълүмат чарасы исеме, чыгу датасы һәм номеры күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чарасының исеме, һәм соратып алына торган мәгълүмат урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы күрсәтелергә мөмкин.

11. Сораштырыла торган мәгълүмат чикләнгән мәгълүматка керсә, Мөрәҗәгатькә җавапта әлеге мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге чикләнгән актның төрен, исемен, номерын һәм кабул итү датасын күрсәтергә кирәк. Сораштырылган мәгълүматның бер өлеше чикләнгән мәгълүматка керсә, ә калган мәгълүмат һәркем өчен мөмкин булган мәгълүмат булып торса, соратыла торган мәгълүмат, чикләнгән мәгълүматтан тыш бирелә.

12. Мөрәҗәгатькә җаваплар мәҗбүри теркәлергә тиеш.

13. Мәгълүмат бирелми, әгәр:

1) Мөрәҗәгать эчтәлеге соралган мәгълүматны билгеләргә мөмкинлек бирми;

2) гаризада почта адресы, электрон почта адресы яисә сорауга җавап җибәрү өчен факс номеры яисә сорауны юллаган мәгълүмат белән элемтәгә керергә мөмкин булган телефон номеры күрсәтелмәгән;

3) соратып алына торган мәгълүмат җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә керми;

4) соратып алына торган мәгълүмат чикләнгән мәгълүматка карый;

5) соратып алына торган мәгълүмат элегрәк мәгълүматтан файдаланучыга бирелгән;

6) Мөрәҗәгатьтә җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән актларны хокукый бәяләү, аның эшчәнлегенә анализ ясау яисә аның ведомствосындагы оешмаларның эшчәнлегенә анализ ясау яки мәгълүматтан файдаланучы мөрәҗәгать җибәргән мәгълүматның хокукларын яклауга бәйле булмаган башка аналитик эш башкару турындагы мәсьәлә куела.

14. Мәгълүмат кулланучыга түләүсез нигездә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

1) телдән формада тапшырыла торган;

2) «Интернет» челтәрендә, шулай ук урнаштыру өчен билгеләнгән урыннарда урнаштырылган;

3) кызыксынучы кулланучының хокукларына һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычларына кагыла торган;

4) закон, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән башкасы.

15. Мәгълүмат биргән өчен түләү соратып алынган һәм алынган мәгълүмат күләме Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән түләүсез нигездә бирелә торган мәгълүмат күләменнән артып китсә, шул ук вакытта мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан соратыла торган документларның һәм (яисә) материалларның күчермәләрен ясауга чыгымнар, шулай ук аларны почта аша җибәрүгә бәйле чыгымнар түләнә. Түләү алу тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

## 12. Мәгълүматтан файдалану хокукын яклау

1. Җирле үзидарә органнарының, аларның вазыйфаи затларының мәгълүматтан файдалану хокукын боза торган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата югарырак вазыйфаи затка яки судка шикаять бирелергә мөмкин.

2. Мәгълүматтан файдалану мөмкинлегеннән хокуксыз баш тарту, яки аны вакытында бирмәү, яисә Мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүмат соратып алуның дөрес булмавы яки тиешле эчтәлегенә туры килми торган мәгълүмат бирү нәтиҗәсендә зыяннар китерелгән булса, мондый югалтулар Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

## 13. Мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүне тикшереп тору

Мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүне җирле үзидарә органы җитәкчесе тиешле җирле үзидарә органнарының хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тикшереп тора.

## 14. Мәгълүматтан файдалану хокукын бозган өчен җаваплылык

Җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары һәм мәгълүматтан файдалану хокукын бозуда гаепле муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, административ, гражданлык һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

Әлки муниципаль
районы Түбән Кәчи
авыл җирлеге
Советының 2015. 12.02.
7№ карарына
2 нче кушымта

**«Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында исемлек**

| т/б № | Мәгълүмат категориясе | Урнаштыру вакыты |
|---|---|---|
| | **I. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында гомуми мәгълүмат** | |
| 1. | Районның җирле үзидарә органнарының тулы һәм кыскартылган исеме, почта адресы, электрон почта адресы, мәгълүматны кулланучылар соратып алу һәм соратып ала торган мәгълүмат алу өчен, белешмә хезмәтенең телефон номерлары, матбугат хезмәте һәм ышаныч телефоны (булганда) | Актуаль халәттә хуплана |
| 2. | Районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләре, аларның структур бүлекчәләренең бурычлары һәм функцияләре турында белешмәләр, шулай ук районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели торган норматив хокукый актлар исемлеге | Тиешле норматив хокукый актлар расланганнан яки үзгәртелгәннән соң 5 эш көне дәвамында. Норматив хокукый актлар исемлеге актуаль хәлдә хуплана |
| 3. | Районның җирле үзидарә органнары һәм аңа буйсынучы оешмалар структурасы | Структура расланганнан яки үзгәртелгәннән соң 5 эш көне дәвамында |
| 4. | Район җитәкчеләре, ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре, аерым алганда, фамилияләре, аталарының исемнәре, шулай ук күрсәтелгән затлар ризалыгы белән алар турында башка белешмәләр турында белешмәләр | Билгеләнгәннән соң 3 эш көне дәвамында. Актуаль халәттә хуплана |
| 5. | Ведомство буйсынуындагы оешмалар исемлеге (булган очракта), аларның бурычлары һәм функцияләре турында белешмәләр, шулай ук почта адреслары, электрон почта адреслары, ведомство буйсынуындагы оешмаларның белешмә хезмәтләре телефоннары номерлары | Оешма төзү турында хокукый акт имзаланганнан соң 5 эш көне эчендә. Актуаль халәттә хуплана |
| 6. | Район тарафыннан гамәлгә куелган (булган очракта) массакүләм мәгълүмат чаралары турында белешмәләр, аерым алганда, гамәлгә куелган массакүләм мәгълүмат чаралары исемлеге, почта адреслары, электрон почта адреслары (булган очракта), телефоннар номеры һәм массакүләм мәгълүмат чараларының рәсми сайтлары адреслары | Массакүләм мәгълүмат чаралары теркәлгәннән соң 5 эш көне дәвамында. Актуаль халәттә хуплана |
| | **II. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норма чыгару эшчәнлеге турында мәгълүмат** | |

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Районның җирле үзидарә органнары чыгарган актлар (карарлар, күрсәтмәләр, кагыйдәләр, инструкцияләр, нигезләмәләр һәм башка актлар), аларга үзгәрешләр кертү, аларны үз көчләрен югалткан дип тану турында белешмәләрне, шулай ук дәүләт теркәве турында белешмәләр | Тиешле документ кабул ителгәннән соң (расланганнан) 5 эш көне дәвамында |
| 8. | Район җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын гамәлдә түгел дип тану турындагы эшләр буенча суд карарлары турындагы белешмәләр | Җирле үзидарә органнарына суд карары чыкканнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 9. | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентлары һәм стандартлары | Аларны раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| **III. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының агымдагы эшчәнлеге турында мәгълүмат** | | |
| 10. | Җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган (башкарыла торган) муниципаль хезмәтләр турында белешмәләр һәм аларны бирү (башкару) тәртибе | Актуаль халәттә хуплана |
| 11. | Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең планнары һәм күрсәткечләре | План яки күрсәткеч расланганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 12. | Федераль максатчан һәм (яисә) дәүләт программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре, максатчан күрсәткечләрне үтәү, финанс ресурсларының максатчан һәм (яисә) дәүләт программасын үтәүгә киткән чыгымнар күләме турында, шулай ук программа чараларын гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләре хакында төп белешмәләр | Квартал саен |
| 13. | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат һәм аналитик материаллар (докладлар, хисаплар һәм мәгълүмат характерындагы күзәтүләр) | Актуаль халәттә хуплана |
| 14. | Районның җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының башка җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, сәяси партияләр, һөнәри берлекләр һәм башка оешмалар, шул исәптән халыкара оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге турында мәгълүмат | Актуаль халәттә хуплана |
| 15. | Регионара шартнамәләрне һәм регионара хезмәттәшлек программаларын гамәлгә ашыруда районның җирле үзидарә органнарының катнашуы турында мәгълүмат | Актуаль халәттә хуплана |
| 16. | Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм рәсми делегацияләренең рәсми очрашулары, шулай ук районның җирле үзидарә органнары оештыра торган рәсми чаралар (утырышлар, очрашулар, брифинглар, семинарлар, "түгәрәк өстәлләр" һәм башка чаралар), аерым алганда, булачак рәсми визитларның һәм эш | Рәсми визит анонслары (эш сәфәре, рәсми чара)<br>- күрсәтелгән чаралар башланыр алдыннан бер эш көне дәвамында. Рәсми визит нәтиҗәләре (эш сәфәре, рәсми чара) |

| | | |
|---|---|---|
| | сәфәрләренең анонслары, рәсми чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат | - күрсәтелгән чаралар тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында |
| 17. | Районның җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм урынбасарларының рәсми чыгыш һәм мөрәҗәгате текстлары | Чыгыштан соң бер эш көне дәвамында |
| 18. | Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәллләрдән яклау торышы һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча күрелгән чаралар, фаразлана торган һәм килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр, халыкны алардан яклау алымнары һәм ысуллары турында мәгълүмат | Актуаль халәттә хуплана |
| 19. | Районның җирле үзидарә органнары үткәрә торган муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында мәгълүмат | Актуаль халәттә хуплана |

**IV. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат**

| | | |
|---|---|---|
| 20. | Җирле үзидарә органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан бүленә торган бюджет акчаларыннан файдалану турында белешмәләр | Квартал саен |
| 21. | заказлар урнаштыру барышы турында статистик мәгълүмат (сату-алуларда катнашучыларның уртача саны, экономия проценты) | Актуаль халәттә хуплана |

**V. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелгән координация һәм киңәшмә органнары турында мәгълүмат**

| | | |
|---|---|---|
| 22. | Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелгән координация һәм киңәшмә органнары исемлеге | Органнар барлыкка килгәннән соң 5 эш көне дәвамында |
| 23. | Координация һәм киңәшмә органнары эшчәнлеген җайга сала торган норматив хокукый һәм башка актлар | Норматив хокукый актларга кул куйганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 24. | Координация һәм киңәшмә органнары составы (фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, координация һәм киңәш бирү органнары җитәкчеләре һәм әгъзаларының вазыйфалары), шулай ук урнашу урыны адресы, телефон номерлары (факс), электрон почта адресы | Норматив хокукый актларга кул куйганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 25. | Координация һәм киңәшмә органнары утырышлары турында мәгълүмат, аерым алганда, утырышларның анонслары, координация һәм киңәшмә органнары утырышларының беркетмәләре | Утырышлар анонслары утырышка кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча. Беркетмәгә кул куйганнан соң 5 эш көне эчендә утырышлар беркетмәсе |

**VI. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарын кадрлар белән тәэмин итү турында мәгълүмат**

| | | |
|---|---|---|
| 26. | Гражданнарның муниципаль хезмәткә керү тәртибе | Актуаль халәттә хуплана |
| 27. | Җирле үзидарә органнарында булган муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында белешмәләр | Вакантлы вазыйфа игълан ителгәннән соң 3 эш көне дәвамында |
| 28. | Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатларга карата квалификация таләпләре | Таләпләр расланганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 29. | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурсларның шартлары һәм нәтиҗәләре | Конкурс шартлары конкурс үткәрелгәнче 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла. Нәтиҗәләр - конкурс үткәрелгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 30. | Җирле үзидарә органында вакантлы вазыйфаларны биләү мәсьәләсе буенча мәгълүмат алырга мөмкин булган телефоннар номеры, электрон почта адресы. | Актуаль халәттә хуплана |
| 31. | Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар оештыру һәм уздыру комиссияләре составы | Комиссия составы расланганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 32. | Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс нәтиҗәләренә карата шикаять белдерү тәртибе | Тәртип расланганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 33. | Җирле үзидарә органнары карамагындагы (булган очракта) мәгариф учреждениеләре исемлеге, аларның почта адресларын, рәсми сайтларның адресларын күрсәтеп, шулай ук әлеге мәгариф учреждениеләре турында белешмә характердагы мәгълүмат алырга мөмкин булган телефон номерлары | Актуаль халәттә хуплана |
| 34. | Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләрнең эш тәртибе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә гаризалар бирү тәртибе | Тәртип расланганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 35. | Җирле үзидарә органында һәм аның карамагындагы оешмаларда коррупциягә каршы көрәш буенча күреләә торган чаралар турында мәгълүмат | Актуаль халәттә хуплана |
| **VII. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының гражданнар (физик затлар), оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләт органнары мөрәҗәгатьләре белән эшләве турында мәгълүмат** | | |
| 36. | Гражданнарның (физик затларның), оешмаларның (юридик затларның), иҗтимагый берләшмәләрнең җирле үзидарә органнарында һәм аның ведомство буйсынуындагы оешмаларда мөрәҗәгатьләре белән эшләү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив | Норматив хокукый һәм башка актны распаганнан соң 5 эш көне дәвамында |

| | | |
|---|---|---|
| | хокукый һәм башка актлар | |
| 37. | Гражданнарның (физик затларның), оешмаларның (юридик затларның), иҗтимагый берләшмәләрнең, дәүләт органнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе | Актуаль халәттә хуплана |
| 38. | Гражданнарны (физик затларны), шул исәптән оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләт органнары вәкилләрен кабул итү тәртибе һәм вакыты | Тәртип расланганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 39. | Вәкаләтләренә гражданнарны, шул исәптән оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләрен кабул итүне оештыру кертелгән структур бүлекчә җитәкчесенең яисә җирле үзидарә органының башка вазыйфаи затының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аларның хәбәрләрен карауны тәэмин итү, шулай ук телефон номеры, белешмә характердагы мәгълүматны алырга мөмкин булган электрон почта адресы | Билгеләнгәннән соң 5 эш көне дәвамында |
| 40. | Гражданнарның, шул исәптән оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләт органнарының мөрәҗәгатьләренә күзәтүләр, шулай ук әлеге мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре һәм кабул ителгән чаралар турында гомумиләштерелгән мәгълүмат | Квартал саен |

**VIII. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы карамагындагы муниципаль мәгълүмат системалары һәм аңа буйсынучы оешмалар турында белешмәләр**

| | | |
|---|---|---|
| 41. | Җирле үзидарә органы һәм аның карамагындагы оешмалар карамагындагы муниципаль мәгълүмат системалары исемлеге | Актуаль халәттә хуплана |
| 42. | Җирле үзидарә органы һәм ведомство оешмалары карамагындагы муниципаль мәгълүмат системаларына кызыксынучы затларның керү шартлары һәм тәртибенә, шул исәптән мәгълүмат системаларыннан файдалана алу яки мәгълүмат системаларыннан белешмәләр алу турында мәгълүматка, белешмәләр алу | Шартларны һәм керү тәртибен раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 43. | Муниципаль мәгълүмат системаларын төзү, алып бару тәртибен җайга сала торган норматив хокукый һәм башка актлар, шулай ук кызыксынучы затларның җирле үзидарә органы һәм аның карамагындагы оешмалар карамагындагы муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматтан файдалану тәртибе | Норматив хокукый актларга һәм башка актларга имза куйганнан соң 5 эш көне дәвамында |
| 44. | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә «Интернет» челтәрендә урнаштырылырга тиешле районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка мәгълүмат | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән срокларда |